МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ _____721/о_____

П Р И К А З Б О Е Р Ы К

«__17___»______12_______2024

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Махсус счет хуҗасы һәм региональ оператор тарафыннан Россия Федерациясе Торак кодексының 177 статьясындагы 7 өлеше һәм 183 статьясы нигезендә тапшырылырга тиешле белешмәләрне бирү тәртибен раслау турында» 2022 елның 31 августындагы 99/о номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Махсус счет хуҗасы һәм региональ оператор тарафыннан Россия Федерациясе Торак кодексының 177 статьясындагы 7 өлеше һәм 183 статьясы нигезендә тапшырылырга тиешле белешмәләрне бирү тәртибен раслау турында» 2022 елның 31 августындагы 99/о номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «, күрсәтелгән затлар тарафыннан бирелергә тиешле башка белешмәләр исемлеге һәм мондый белешмәләрне бирү тәртибе» сүзләрен өстәргә;

боерыкның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Кушымталарда бирелгәннәрне расларга:

Махсус счет хуҗасы һәм региональ оператор тарафыннан Россия Федерациясе Торак кодексының 177 статьясындагы 7 өлеше һәм 183 статьясы нигезендә тапшырылырга тиешле белешмәләрне бирү тәртибе;

Махсус счет хуҗасы һәм региональ оператор тарафыннан тапшырылырга тиешле башка белешмәләр исемлеге;

Махсус счет хуҗасы һәм региональ оператор тарафыннан тапшырылырга тиешле башка белешмәләрне бирү тәртибе.»;

4 пунктта «министрның беренче урынбасары А.М.Фроловны» сүзләрен «министр урынбасары М.Х.Салиховны» сүзләренә алмаштырырга.

2. Юридик бүлеккә (Р.И. Кузьминга) дәүләт теркәвенә алу өчен әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторына (Р.Җ.Зәйнуллинага) әлеге боерыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары М.Х.Салиховка йөкләргә.

Министр М.М.Айзатуллин

Отдел контроля исполнения документов

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2022 елның 31 августындагы 99/о номерлы боерыгы белән расланды
(Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2024 елның 17 декабрендәге 721/о номерлы боерыгы редакциясендә)

Махсус счет хуҗасы һәм региональ оператор тарафыннан тапшырылырга тиешле башка белешмәләр исемлеге

1. Махсус счет шартнамәсе шартлары турында.
2. Гомуми мөлкәткә капиталь ремонт кертемнәрен түләү буенча күпфатирлы йорттагы һәр милекченең бурычының күләме турында.
3. Күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлауга кертемнәрне түләү бурычының тиешенчә үтәлмәвенә бәйле рәвештә күпфатирлы йорттагы урынның һәр милекчесенә исәпләнгән һәм аның тарафыннан түләнгән процентлар күләме турында.
4. Акчалардан файдаланган өчен исәпләнгән процентлар күләме һәм махсус счет шартнамәсе шартлары нигезендә исәптән чыгарылган комиссия түләве суммасы турында.
5. Махсус счеттагы акчаларга махсус счет хуҗасының Россия Федерациясе Торак кодексының 44 статьясындагы 2 өлешенең $1^2$ пунктында күрсәтелгән күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми җыелышы карарлары нигезендә төзелгән шартнамәләрдән, шулай ук күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми җыелышының капиталь ремонт үткәрү турындагы карары нигезендә яисә башка законлы нигездә шушы күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәтләр күрсәтүгә һәм (яисә) эшләр башкаруга төзелгән шартнамәләрдән килеп чыга торган йөкләмәләре буенча түләтү әйләнеше турында.
6. Россия Федерациясе Торак кодексының 181 статьясындагы 4 өлеше нигезендә капиталь ремонт өчен кертемнәр түләү буенча йөкләмәләрне киләчәк чорга үтәү исәбенә региональ оператор тарафыннан акча кертү турында.
7. Капиталь ремонт буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яисә) эшләр башкару өчен җәлеп ителгән подряд оешмалары белән төзелгән шартнамәләр турында.
8. Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча күрсәтелгән хезмәтләрне һәм (яисә) башкарылган эшләрне кабул итү турында.
9. Күпфатирлы йортны җимерү яки реконструкцияләү максатларына капиталь ремонт фонды акчаларын күчерү турында.

10. Авария хәлендә дип танылган һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле күпфатирлы йорт урнашкан җир кишәрлеген дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен алган һәм тиешенчә шушы күпфатирлы йорттагы һәр торак урынны алган очракта, күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренә капиталь ремонт фонды акчаларын күчерү турында.

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2022 елның 31 августындагы 99/о номерлы боерыгы белән расланды
(Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2024 елның 17 декабрендәге 721/о номерлы боерыгы редакциясендә)

Махсус счет хуҗасы һәм региональ оператор тарафыннан тапшырылырга тиешле башка белешмәләрне бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип махсус счет хуҗасы һәм региональ оператор тарафыннан тапшырылырга тиешле башка белешмәләр исемлегендә булган белешмәләрне бирү механизмын билгели.

2. Белешмәләр түбәндәге затларга (алга таба – соратуны гамәлгә ашыручы затлар) бирелә:

а) күпфатирлы йорттагы урын милекчесенә;

б) күпфатирлы йорт белән идарә итү өчен җаваплы затка (торак милекчеләре ширкәтенә, торак кооперативына, махсуслаштырылган башка кулланучылар кооперативына, идарәче оешмага);

в) күпфатирлы йорт белән турыдан-туры бу күпфатирлы йорттагы биналарның милекчеләре идарә иткән очракта, күпфатирлы йорттагы биналарның милекчеләренең гомуми җыелышы карары белән билгеләнгән мондый йорттагы биналарның милекчеләренең берсенә яки мондый йорттагы биналарның барлык яисә күпчелек милекчеләре тарафыннан язмача формада бирелгән, ышаныч кәгазе белән таныкланган вәкаләте булган башка затка;

г) дәүләт торак күзәтчелеге органына.

3. Белешмәләр бирү турындагы гариза (алга таба – гариза) махсус счет хуҗасына, региональ операторга кәгазь чыганакта яки, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен кулланып, электрон формада җибәрелә һәм анда түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

гаризаны гамәлгә ашыра торган физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) яисә юридик затның тулы атамасы, төп дәүләт теркәү номеры, салым түләүченең тәңгәллек номеры;

үзенә карата белешмәләр сорала торган күпфатирлы йортның адресы;

сорала торган белешмәләрнең конкрет төренә һәм мәгълүмат бирелергә тиешле датага (чорга) күрсәтү;

сорала торган мәгълүматны алу формасы (шәхси мөрәҗәгать иткәндә алына торган кәгазь документ; почта аша алына торган кәгазь документ; электрон почта аша алына торган электрон документ);

мәгълүматны җибәрү кирәк булган почта адресы (электрон адрес – булган очракта);

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль закон нигезләмәләренә туры китереп, гаризаны гамәлгә ашыра торган зат тарафыннан тапшырылган шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык.

4. Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

1) әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән затлар тарафыннан:

гаризаны гамәлгә ашыручы затның Россия Федерациясе законнары нигезендә милек хокукын раслаучы документ күчермәсе;

2) әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән затлар тарафыннан:

законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланган күпфатирлы йорт белән идарә итү шартнамәсенең күчермәсе (гариза идарәче оешма тарафыннан бирелгән очракта);

законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланган устав күчермәсе (гариза торак милекчеләре ширкәте, торак кооперативы, махсуслаштырылган башка кулланучылар кооперативы тарафыннан бирелгән очракта);

3) әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы «в» пунктчасында күрсәтелгән затлар тарафыннан:

күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми җыелышы карары күчермәсе яисә законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланган ышанычнамә күчермәсе.

5. Махсус счет хуҗасы, региональ оператор гаризаны һәм аңа беркетелә торган документларны кергән көнне теркиләр һәм теркәлгән көннән башлап ун эш көне эчендә аларны тикшерәләр һәм гаризаны гамәлгә ашыра торган затларга сорала торган белешмәләрне бирәләр яисә, әлеге Тәртипнең 6 пунктында каралган нигезләр булган очракта, белешмәләрне бирүдән баш тарталар.

6. Белешмәләрне бирүдән баш тарту нигезләре булып түбәндәгеләр тора:

белешмәләрнең әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелмәгән затлар тарафыннан соратылуы;

гаризаның бу Тәртипнең 3 пунктына туры килмәве;

әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән документларның тапшырылмавы яки тулы күләмендә тапшырылмавы;

тапшырылган документларда дөрес булмаган белешмәләр булуы. Дөрес булмаган белешмәләр дигәндә тапшырылган документларда чынбарлыкка туры килмәгән мәгълүматның булуы турында сүз бара;

махсус счет хуҗасы һәм региональ оператор тарафыннан тапшырылырга тиешле башка белешмәләр исемлегендә каралмаган мәгълүматның соратылуы.

7. Сорала торган белешмәләр (белешмәләр бирүдән баш тарту турында белдерү) махсус счет хуҗасы, региональ оператор тарафыннан почта адресына язмача формада почта аша җибәреп яки гаризада күрсәтелгән адреска электрон рәвештә җибәрелә яисә, гаризада күрсәтелгән сорала торган белешмәләрне алу ысулына бәйле рәвештә, шәхсән тапшырылалар. Белешмәләр бирүдән баш тарткан очракта, белдерүдә мондый баш тартуның сәбәбе күрсәтелә.

8. Сорала торган белешмәләр бушлай бирелә.